**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_____________ ПР-283 29.12.2025 №____

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы "Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия" муниципаль бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне яңа редакциядә, Актаныш муниципаль районы башкарма комитетларының баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәне (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) яңа редакциядә» раслау хакында" 2024 елның 21 мартындагы ПР-51 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы "Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия" муниципаль бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы "Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия" муниципаль бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" җитәкчеләре һәм белгечләренең вазифаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сумнарда | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органы) структур бүлекчәсе булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение | 40 700 | |

| | | |
|---|---|---|
| җитәкчесе | | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары, баш бухгалтер | 38 100 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 38 100 |
| Бүлек башлыгы | 33 600 | 33 600 |
| Әйдәүче бухгалтер | 30 600 | 30 600 |
| Әйдәүче икътисадчы | 30 600 | 30 600 |
| Әйдәп баручы белгеч, программист | 30 600 | 30 600 |
| Сатып алулар буенча белгеч | 30 600 | 30 600 |
| Кадрлар буенча белгеч | 29 000 | 29 000 |
| Бухгалтер | 29 000 | 29 000 |
| Эш башкаручы | 29 000 | 29 000 |

1.2. Нигезләмәнең 6 нчы пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы "Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия" муниципаль бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең еллык хезмәт хакы фондын формалаштырганда исәпкә алына:

1) бер елга исәпләнгән 12 вазыйфаи окладтан чыгып, җитәкчегә һәм белгечкә айга вазыйфаи окладлар түләүгә акчалар суммасы (Od).

2) 0,3*Od еллар хезмәте өчен айлыклык өстәмә түләүгә, эш интенсивлыгы өчен айлык өстәмә, еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр түләү, матди ярдәм (елга 12 ай исәбеннән) өчен акча суммасы.

3) Җитәкчеләр һәм белгечләрнең штат саны

4) Хезмәткә түләү буенча түләүләргә исәпләүләр.»

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча http:/aktanysh.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе А.А.Корбангалинага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев